**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 24 сентябрендәге 3155 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 12 апрелендәге 1541 номерлы карары белән расланган «Яңа Порт» гидротехник корылмасы, 2нче этап» җирле әһәмияттәге линия объекты территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45 һәм 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы «Территорияне планлаштыру документларын, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, килештерү, раслау, аларның гамәлдә булу вакытларын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр, файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023, 2024 һәм 2025 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына таянып, «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе гаризасы нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 12 апрелендәге 1541 номерлы карары белән расланган «Яңа Порт» гидротехник корылмасы (2 нче этап)» җирле әһәмияттәге линия объекты территориясен планлаштыру проектына, әлеге карарның кушымтасы нигезендә территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслау юлы белән, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми

мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 24 сентябрендәге
3155 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 12 апрелендәге 1541 номерлы карары белән расланган**
**«Яңа Порт» гидротехник корылмасы (2нче этап)» җирле әһәмияттәге**
**линия объекты территориясен планлаштыру проектына кертелә торган**
**үзгәрешләр**

1. Линия объектын урнаштыру турындагы нигезләмәдә «Мәҗбүри алынырга (резервланырга) тиешле җир кишәрлекләре исемлеге» дигән 4 бүлектә:

1.1. 1 юлда «Өлешчә мәҗбүри алу» сүзләрен «Резервлау» сүзенә алмаштырырга;

1.2. 2 юлда «Объектның кадастр номеры, билгеләнеше, исәп номеры» графасын яңа редакциядә бирергә: «16:50:080704:22 (ЕЗ 16:50:000000:327)»;

1.3. 4, 10, 11 юлларда «Өлешчә мәҗбүри алу» сүзләрен «Тулысынча мәҗбүри алу» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. түбәндәге эчтәлекле 14 юл өстәргә:

| № т/б | Объектның кадастр номеры, билгеләнеше, исәп номеры | Җир кишәрлеге-нең мәйданы, кв.м | Ясала торган җир кишәрлегенең рөхсәт ителгән файдалану төре | Мәҗбүри алу/резервлау |
|---|---|---|---|---|
| «14 | 16:50:000000:21254 | 1390 | Гидротехник корылма (код 11.3) | Резервлау» |